# Сыйфатлы белем һәм яхшы тәрбия – ышанычлы киләчәк!



***Ләйсинә Расиловна Мөхәмәдиева, Кубәк урта гомуми белем бирү мәктәбе директоры.***


“Күп белдерүгә караганда, үз белдереп, эзләнү орлыгын салу һәм эзләү юлларын табарга өйрәтү – мөгаллим бирә ала торган хезмәтләрнең иң зурысы”, – дигән мәгърифәтче һәм галим Г.Ибраһимов

Белем һәм тәрбия сыйфаты, аларга йогынты ясаучы факторлар турында уйланмаган кеше сирәктер, мөгаен. Чөнки кешелекнең яшәү сыйфаты да мәгариф системасының һәм, аерым алганда, белем оешмаларының торышына турыдан-туры бәйле.

Кубәк урта гомуми белем бирү мәктәбе 9 авылдан килгән балаларга белем һәм тәрбия бирә. Коллективта 23 педагог, 12 техник хезмәткәр эшли. Укытучылырның 97 % югары белемле, 3 е югары 18 беренче категорияле укытучылар: ир-атлар - 17 %, хатын-кызлар 83 % тәшкил итә. Сыйфатлы белем һәм тәрбия бирү өчен педагоглар потенциалы җитәрлек.

Коллективның уртача яше (41) дә, уртача хезмәт стажы (19) да шактый зур. Бу берьяклап тупланган тәҗрибә зур булуын күрсәтсә, икенче яклап пенсия яшенә җитүчеләр дә булуын аңлата. Соңгы елларда мәктәпләр кадрлар кытлыгы кичерә, бу авырлык безнең мәктәпне дә читләтеп үтми. Рус теле һәм әдәбияты, информатика укытучылары юк. Гомумән, 11 укытучы башка авыллардан йөреп укыта.

Кадрлардан кала укыту сыйфатына йогынты ясаучы факторларның тагын берсе - материаль-техник база. Федераль дәүләт белем бирү стандартларын тормышка ашыру да мәгариф оешмаларының матди-техник базасын ныгытырга зур таләпләр куя.

Күбәк мәктәбенә 2012 нче елда 4 позиция: түбә, ишекләр, тәрәзәләр, җылылык системасы буенча ремонт керде. 2013 нче елда “Уңайлы мохит” республика программасы буенча җиһазландырылды. 2019 нчы да исә ашханә өлеше ремонтланды. 2020 нче елда Октябрь филиалында ремонт эшләре алып барылды.  Күбәк урта мәктәбендә грант акчасына кабинетларга проекцион комплектлар алынды. 2021 нче елда “Үсеш ноктасы” программасы кысаларында химия, биология, физика кабинетларына ремонт эшләре үткәрелә.

Укытучыларның осталыкларын арттыру максатында методик берләшмәләр эшләп килә. Алар узара дәресләргә керүне, анализлауны оештыра. Андый чараларда һәркем үзенә тәҗрибә туплый, профессиональ яктан чарлана.

Укытучылар төрле чараларда катнаша һәм югары күрсәткечләргә ирешә. Олимпиада нәтиҗәләре үсештә булуы куандыра, соңгы елларда республика күләмендә дә призлы урыннарыбыз бар. Укучыларның төрле фәнни-гамәли конференцияләрдә, сәнгать конкурсларында катнашулары да аларга һәрьяклап үсәргә мөмкинлек тудыра. Димәк, сәләтле балалар белән эшчәнлек тиешле дәрәҗәдә оештырыла.

Һәр уку елында аерым үрнәктәге аттестат алучы укучылар булуы да куанычлы.

Өстәмә белем бирү өчен мәктәпнең лицензиясе бар. Балалар 100% дәрестән тыш эшчәнлеккә, өстәмә белем бирү дәресләренә тартылган. 2010 нчы елдан, мәктәптә барлык укучылар да, 2 тапкыр кайнар аш белән тәэмин ителгән.

Балаларга белем бирүдә мәктәп китапханәсенең  эшчәнлеген уңай яктан билгеләп үтү кирәк. Китапханә фонды иске булса да, шактый зур. Җитмәгән дәреслекләр Яр чаллы шәһәре мәктәпләре белән элемтәгә кереп туплана.

Мәктәп, балаларны үз милләтенең вәкиле итеп тәрбияләп, татар җәмгыятендә милли үзаң формалаштыру, үстерү ягыннан әйдәп баручыга

әйләнергә тиеш. Милли тәрбияне үстерү мәсьәләсе яңа проблема түгел. Ул бигрәк тә XX йөз башында үсеш ала. Милли тәрбия телне үстерү, саклау, милли үзаң формалаштыру белән тыгыз бәйләнгән. Милли үзаң тел белүдән киңрәк, мөһимрәк, ул кешенең милләт вәкиле һәм шәхес буларак тәрбияләнүе дигән сүз. Коллектив милләт вәкиле буларак үзбилгеләнү шәхестә үзенә ышыныч уятуын, милли мәдәниятне белү башка мәдәниятләргә юл ачуын аңлап эш итә. Шулай ук милли мәдәният һәм әдәбиятны өйрәнү буенча республикакүләм фәнни-гамәли конференцияләрдә уңышлы чыгыш ясаган укучы, укытучыларыбызның эшләре төрле җыентыкларда дөнья күрде. Хезмәтнең нәтиҗәсе булуы, бу юнәлештә эшчәнлегебезнең дөрес булуын ассызыклый. Мәктәп, 2020 нче елда “Татарстан Республикасы муниципаль бюджет гомуми белем бирү оешмаларында туган телдә (татар, мари, удмурт, чуаш, мордва) белем бирүнең иң яхшы тәҗрибәләре” республика конкурсында катнашып, 500 меңлек сертификатка ия булды. Аның ярдәмендә барлык кабинетларга да проекцион комплект алынды. Милли бизәкле стендлар, мәгърифәтчеләрнең портретлары кайтартылды.

Шәхесне рухи-әхлакый яктан формалаштыруда бер хәлиткеч фактор бар. Ул - көн саен яңарып тора торган тормыш шартлары. Шунлыктан мәктәптә социальләшүгә зур урын бирелә. Мәктәпләрдә өстәл китабы булып торучы Мөслим муниципаль районының 2019-2023 елларга рухи һәм әхлакый үсеш программасының “Тәрбияле бала – ышанычлы киләчәк” юнәлеше дә шул максатка хезмәт итә. Безнең бурыч - баланы ирекле шәхес булып үсәргә, иң кирәкле рухи кыйммәтләрне сайлап ала һәм аларны тормышта максатчан куллана белергә өйрәтү. Менә без шушы проблема өстендә эшләүне үзебезгә бурыч итеп алдык.

Укучыларны вакыт ритмында тәрбияләүдә “Әхлак дәресләре”, “Тормыш дәресләре” проекты үзен аклый. Иң мөһиме – тәрбияне тормыш сабаклары аша җиткерү, димәк, очрашулар, экскурсияләр, гамәли дәресләр

куллану. Әлеге дәресләрдә белемнәр тормыш белән бәйләнеп, һөнәри юнәлешкә дә зур игътибар бирелә.

2015 нче уку елында педагогик коллектив, эш юнәлешендә мөһим алым итеп, укытучыларның проект эшчәнлеген куллануны кабул итте. Һәр укытучы дәресләрдә әлеге юнәлеш буенча эш оештыра. Проектлар технологиясе мөстәкыйль фикерләүне үстерү, мәгълүмат таба белү, фаразлау, стандарт булмаган карарлар кабул итү осталыгына ия булуны күздә тота. Проектлаштыру ысулы төрле өлкәгә караган белемне интегральләштерергә һәм аларны, яңа идеяләргә баетып, тормышта кулланырга мөмкинлек бирә.

2016 нчы елда мәгариф бүлеге дирекция алдына Күбәк, Әмәкәй һәм Баек мәктәпләрен берләштереп, Күбәк база мәйданчыгын булдыру бурычын куйды. Төп максат алдынгы инновацион тәҗрибәне өйрәнү һәм кулланышка кертү юнәлешендә эш оештыру. Әлеге максатка ирешү юлында база мәйданчыгы “Мәктәптә белем сыйфатын күтәрүдә педагогик проектларның роле” темасын билгеләде. Мәктәпләр арасында үзара ярдәмләшү оештырылды, бер-берсендә булган яңалыклар өйрәнелде һәм белем бирү процессында кулланышка кертелде. Беренче елны мәктәпләр базасында оештырылган семинар-киңәшмәләр, үзара дәресләргә керү, мастер-класслар үткәрү, алдынгы тәҗрибә урталашу максатына ирешелде. Икенче уку елында укучылар делегацияләре белән дә чаралар планга кертелде. Үткәрелгән һәр чара алдагы эшләрдә уңай чагылыш табуы белән куанычлы. Әмәкәй һәм Баек төп гомуми белем бирү мәктәбе укучылары 10 нчы сыйныфка белем алырга, Күбәк урта мәктәбенә килделәр.

Проект эшчәнлеге һәр өч мәктәптә дә уңышлы алып барыла. Укытучылар белем бирү процессында проект эшчәнлеге нигезендә белем сыйфатын күтәрү ятуын анык күзаллыйлар. Филология һәм гуманитар фән укытучыларының 85 % (20/17) ы проект эшчәнлеге нигезендә эшен оештырса, башлангыч класс укытучылары 77% (13/10), төгәл фән укытучылары 67 % (15/10) үз эшләрен проект юнәлеше белән бәйләп алып бара. Эш юнәлешен проект эшчәнлеге белән бәйләүдә ялгышмаганбыз дип

эйтергэ тулы нигез бар. Укытучыларның дәрестә инновацион технологияләр куллануы укучыларның белем сыйфатында да чагылыш таба.  Укытучыда да, укучыда да теоретик белемнәрне гамәлдә куллану күнекмәсе үсә. Проектта һәрбер кешегә файдалы гамәли тәҗрибә үрнәкләре бирүгә ирешелә.

База мәйданчыгында эшләү  укытучыларның аралаша белү күнекмәләрен камилләштерү, үзара дустанә хезмәттәшлек күпере булдыруда да ярдәм итә.

2020 нче елда Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы тарафыннана үткәрелгән беренче региональ “Мәгарифтә белем күтәрүнең мәктәп программалары конкурсы”нда катнашып, икенче дәрәҗә дипломга лаек булды.   Шәхескә юнәлтелгән мәгълүмати-коммуникатив технологияләрне куллану укытуның сыйфатын күтәрергә ярдәм итә, этәргеч бирә.

Һәрбер укытучы - үз эшенә мөкиббән шәхес. Һөнәри осталыкларының сере дә балалар күңеленә юл табып, аларны фән һәм белем дөньясына алып кереп китә белүдәдер. Укучы, укытучы яулый алмаган биеклекләр юк, тик баскычны дөрес урынга куя белергә генә кирәк.

“Яулап алу җиңел, шул яуланганны саклап тота белү авыррак”, - ди безнең халык. Безнең миссия – “Сыйфатлы белем һәм яхшы тәрбия –ышанычлы киләчәк!”